ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Мира, д.11А,пос.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“20” сентября 2017 г. — № 39

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1.Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:**

«Мамадыш» совхозының 2нче фермасы торак пунктында, Рус Пакшины торак пунктында су күтәрү манарасын алыштыру;

су белән тәэмин итү линиясен алмаштыру Рус Пакшины торак пунктында, Керэшен Пакшин торак пунктында

2. **Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

Максим Починок, Ташлы авыллары торак пунктында күперне ремонтлау,;

Кызыл Тау авыл җирлеге торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту һәм грейдировкалау

**3. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**
янгын гидранты җайланмасын сатып алу һәм урнаштыру
Максимов Починок торак пунктында,
Ташлы авыллары торак пунктында,
Керэшен Пакшин торак пунктында,
Рус Пакшины торак пунктында.
«ӘЙЕ» «ЮК»
2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы В. В.А.Гиззатуллинага йөкләргә.

Красногорск авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Гыйззәтуллина В.А.